| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 1 августыннан №30

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 5 июнендәге 23 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның естәмә нигезләрен билгеләү турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Туктар-Урдаласы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 5 июнендәге 23 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта 10, 11, 12), 13) пунктчаларын тешереп калдырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет урамы, 98 йорт, Совет урамы, 103 йорт, Карагай авылы, Тельман урамы, 31 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.https://leninogorsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Ә. Әхмәтова